| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**20.08.2018** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№1680** |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2018 елның 28 августындагы 1369 карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларын норматив финанслау турында» 2017 елның 08 августындагы 566 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында 2018 елның 27 июлендәге 605 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2018 елның 28 июнендәге 1369 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында балаларга һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алу хокукларын гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнарны исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 таблицаны 39 нчы юл белән тулыландырырга:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «39. | Техник, электрон укыту чаралары | параллельгә 1берәмлек | 5 ел». |

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Д.А. Сапожников